Республика Татарстан
Глава Тураевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района

423647, Менделеевский район, с.Тураево,
ул. Центральная, д 11а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге Башлыгы

423673, Менделеевск районы, Турай авылы,
Үзәк урамы, 11а

тел./факс 8/85549/2-73-31, E-mail: Tur.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/turaevskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 нче елның 12 нче декабрендәге 2 нче номерлы карары

Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлегенең Турай
авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча халык
җыены үткәрү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131 нче номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 ст., 2004 елның 28 июлендәге 45 нче номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. 2021 елның 21 декабрендә 10 сәгать 00 минутта Турай авыл җирлегенең Турай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2021 елның 21 декабрендә 11 сәгать 00 минутта Турай авыл җирлегенең Турай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә
3. 2021 елның 21 декабрендә 12 сәгать 00 минутта Турай авыл җирлегенең Турай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә
4. 2021 елның 21 декабрендә 12 сәгать 00 минутта Турай авыл җирлегенең Турай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын билгеләргә

Җыеннарның барлык этапларын үткәрү урыны итеп Турай авылы, Үзәк урамы, 11А йорты адресы буенча урнашкан Турай авыл мәдәният йорты билгеләргә.

Турай авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына бүлү территориаль билге буенча киләсе тәртиптә башкарыла:

Беренче этап: Кама урамы 1нче йорттан 4нче йортка кадәр, Яңа урам 1нче йорттан 3нче йортка кадәр, Яшьләр урамы 8, 10, 21нче йортлар, Окольная урамы 1нче йорттан 37нче йортка кадәр.

Икенче этап: Чокырлы урам 1нче йорттан 37 нче йортка кадәр, Совет урамы 1 нче йорттан 33 нче йортка кадәр.

Өченче этап: Үзәк урамнан 1 нче йорттан 44 нче йортка кадәр, Актык урамы 1 нче йорттан 33нче йортка кадәр.

Дүртенче этап: Тынычлык урамы 1нче йорттан 18 нче йортка кадәр, Мәктәп урамы 1нче йорттан 12нче йортка кадәр.

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылы территориясенддә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешегә 300 сум күләмендә акча билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- генератор, Турай авыл зираты сугым чүкеч сатып алу ;
- Турай авылы су башнясы территориясен төзекләндерү

“Риза” “каршы”

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында Турай авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә. www.mendeleevsk.tatar.ru

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Турай авыл җирлеге башлыгы Рәхимова А.М.